**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Дуртмунчинского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Молодежная, д.148, с Дурт-Мунча,
Заинский район, (423515)
тел. 6-03-10

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 148 нче йорт,
Дүрт Мунча авылы Зәй районы
(423515) тел. 6-03-10

Телефон, факс 60 3 10. Электронный адрес: Durt.Zai@tatar.ru, сайт: www. durtmuncha.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**02.02.2022г.** **№2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гаварендәге 57 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2022 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" 2021 елның 05 февралендәге 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй

муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Р.Т. Ситдиков**

Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
башкарма комитетының
«02» февраль 2021ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 01 февраленнән
Дүрт-Мунча авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе** *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 649,00 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 132,25 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 183,43 |
| Барысы | 6964,68 |

Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
башкарма комитетының
«02» февраль 2021 ел
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

Дүрт-Мунча авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 726,37 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 976,90 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 105,18 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 156,23 |
| Барысы | 6 964,68 |